РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

Тезучеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 1 сентябре № 42

Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукларыннан, оператив идарә хокукларыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә ия булуга һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 38 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше, 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалаган күчемсез милекне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукларыннан, оператив идарә хокукларыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), хокукларыннан азат булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга озак сроклы нигездә ия булуга һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген раслау турында» 2017 елның 15 декабрендәге 38 номерлы карарына кушымтага, әлеге карарга кушымта нигезендә аңа мөлкәт өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
42 номерлы карарына кушымта

| т/с | Адрес | Исәпкә алу объектының исеме | Объектның характеристикасы, мәйданы, кв. м |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Студентлар ур., 13 йорт, 1008 урын | 1008 нче торак булмаган урын KN16:53:040205:2588 | 581,5 кв.м мәйданлы торак булмаган урын административ бинаның 4 катында урнашкан |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

М.В. Камелина